During the flood, obviously, not only people and goods, farms, but also the works that represented the cultural value of that time were washed away. Among them were books. We should not forget this either: until the beginning of the 19th century, the tsarist government did not give permission to the Tatars to print books, which is why during the flood in Ura we had few printed books, and the written works were copied from hand to hand. Thus, each book was very valuable and expensive. Ura had long been a town of scholars, religious figures and madrasahs. Therefore, its name was Ura noble. In Ura, there was a grave of the famous 17th century writer and scientist Yunus Ivanai akhun[5]. During the flood in Ura, there was the aforementioned well-known teacher Fathulla akhun[6], as well as other akhuns – religious figures, even Khabibulla ishan[7], who found his followers in the Penza and Simbirsk provinces. There were madrasahs and modern scholars. Consequently, during the disaster in Ura, there were a lot of manuscripts of historical value, records and textbooks. Therefore, when the town flowed away, along with people, many things and books that fell into the stream were also washed away. In some versions of the bayt, this fact is mentioned. Seeing this, the students of the madrasah were most worried. Here's the remarkable thing: if they showed their worries about the loss of books when the authorities of the colonial royal state came to investigate such a serious event as a flooded town, the missionaries behind them would learn this, so this could not happen. In the bayt, the representatives of the authorities are called atheists by their religious affiliation, and the bayt describes that the students did not reveal their "secret" to them. The students are called "talips" (those who study) in the bayt. Here are a few lines about them:

Taliplarnen zararyn
(Damage caused to those who learn)
Khichber kafer belmade.
(The atheists did not understand at all).
Kitaplarnyn kodraten
(The power of books)
Khich bereve sizmade.
(None of them realized it.)

Kup Korannar agyptyr,
(Many Qurans were washed away,)
Kup Kitaplar agiptyr,
(Many books were lost.)
Any kurgan taliplar
(The students who saw it)
Zar va goryan[8] buliptyr.
(They were very worried and cried.)

Taliplar kup eglady,
(The students cried a lot)
Ostazlaryn zhallade,
(Pitying their teachers,)
Ber Allaga doga kylyp,
(they only prayed to Allah)
Zhomla khayran aylade.
(And were shocked.)

Thus, these lines, even taking into account the time and religious aspects, reveal the attitude towards scientific books that fell victim of flooding, towards the cultural heritage, and the students' view of this catastrophe as a spiritual catastrophe of the country; at the same time, we see that the students did not tell the missionaries of Kazan about the books, as they had wished to destroy these books, like the flood had done.

*How is an evening at Ura in 1872 described?*

"Despite the fact that the weather was damp and it was dark, in the bey's factories the light was bright illuminating all the streets. You could hear

[5] Yunus Ivanai akhun – a religious figure, imam-khatip in the village of Verkhnyaya Ura (now the Arsk region of Tatarstan), imam-khatip, teacher (1639 – 1689/1690) [24, p. 40–41]. – *M. Kh.*

[6] Fathulla akhun – Fathulla ibn al-Husain al-Oryvi (1767/1768 - 1843), a religious figure [25, p. 6-10]. – *M. Kh.*

[7] Khabibulla ishan – Khabibullah ibn Khusain al-Oryvi al-Bulgari (1762 – 1818), a religious figure [24, p. 84–85]. – *M. Kh.*

[8] *Goryan* – the one who cries out loud. (*Note by Naki Isanbet*)

the noise of the guards in the beys' backyards, the barking of big dogs, the ringing voices of the guards in the streets, you could hear the passing coachmen urging their horses to run faster, the recruits walking along the streets, the accordion playing, the shouting and whistling, and after all, if Ura was called the town, it, naturally, was not a town in the modern sense of the word. There were no high-rise buildings, trams and cars, or paved roads. But it was not a village at that time either. It was a manufacturing town that produced capitalist goods. It was unlike any other village close to it. I might have been a town in its appearance reminiscent of the life in Kazanskaya Sloboda, in or one of the counties. For example, in the small book "Shahri Kazana sayakhat" ("A Journey to the City of Kazan") [26] [9], the evening in Ura in 1872 is described as follows:

"... We went out into the street. The voices of the manufacturers merged with the voices of countless ducks and geese that were sitting on both banks of the river, and went far beyond the clouds."

This was the Ura of the 1870s. At this time, there were only two factories in Ura. In the last century, there were 6-7 factories in Ura, I think the reader can imagine how stormy the life was there at that time.

Since this was a town, there were not only wooden houses, but also stone buildings and shops. If they were there, in Sharifzhan Gabdullovich's memoir notebook they were described in this way:

"The stone barns, the warehouses of the rich were full of astrakhan, coarse calico, countless cotton, in the stone cellars there was even sheep stomach fat brought from Kazakhstan."

"The believing rich man, Khuzha Saetov, also had a large stone basement. The wealthy residents even dreamed of minting money. Sadyk Khuzha Sayetov[10] had a factory made of stone, he employed many workers. Gates, fences, warehouses, shops – everything was made of stone, in every stone shop there was some product sold" [11].

As we can see from here, at the beginning and in the middle of the last century, there were both wooden and stone houses in Ura; in general, it looked like the Old Tatar settlement in Kazan.

At the same time, do not think that Ura was completely different from the old villages, not at all. In the same place, some residents were engaged in agriculture, kept livestock, had gardens, took out a herd in the morning to graze, meeting it in the evening. (However, when in 1938 I went to Ura, in Kazan itself they continued to keep cows, so the fact that the same thing happened in Ura did not violate its town status.) Some rich people also had herds of horses. There were forests everywhere where they had dachas, the forests of Bitaman, Zhanbai, Nirti were in the possession of the Ura rich. On the territory of 50 - 60 versts, there was a match factory and a paper factory near the Mari village of Unchy.

Thus, since the rich of Ura had no other means of transport than horses, they were not occupied exclusively by factory farms, they kept horse farms out of the town. Horses were also needed for slaughter. Also, away from Ura, they had their manufactures such as a matchmaking and a paper factory.

*Days off – holidays*

As you know, in tsarist Russia, weekends and holidays, for example, Sunday, and the beginning of the year – Christmas, fell on religious dates in the Christian calendar. In the town of Ura, working days and holidays, including Maulit (the birthday of the Prophet Muhammad) and other holidays, were celebrated not according to the state calendar, but according to their traditions and customs. At the same time, the weekly weekend – Friday, then the holidays of Uraza (the end of the lent), Kurban Bayram, Maulet (the birthday of the Prophet Muhammad) and other ceremonies were celebrated magnificently and in the style characteristic of Tatar manufacturing. The manufacturers used these celebrations very skillfully to advertise their goods and their success.

**Friday.** "On Friday, women and children from neighboring villages bring crops (an oblong shock, a stack of bread) to the factories, all the streets, the territory near the factories, the houses of the rich are filled with women and men dressed in a variety of red, green, blue, white, black, and yellow clothes (made of the factory produce – *N. I.*). Because they bring to the factories the work they took the previous Friday to do, they come to the houses of the rich to get paid for the work and take another piece of work. And in this way a motley, amazing spectacle, a hype is born" [11].

---

[9] "Shahri Kazana sayakhat" ("A Journey to the City of Kazan"), 1902, the author. B.G. S.S. (These letters are shown because our alphabet lacked the letters.) *(Note by Naki Isanbet)*

[10] Sharifzhan Gabdullovich studied in Ura in 1850-1870. From his handwritten notebook, we learn what he himself saw, knew and heard from his ancestors. *(Note by Naki Isanbet)*

As you can see, the manufacturers of Ura partially supplied the neighboring villages with work, and under the pretext of giving them a day off on Friday, made Friday a “holiday” for handing over their work and receiving new orders.

Secondly, from this event, we see that the factories of Ura ensured that the Tatar women were not locked up at home under their husbands’ rule, but went out with their husbands to give in their work. Even though their mullahs studied in Bukhara, these were not the deeds and events of Bukhara practiced by the locals. First of all, this was reflected in how they spent the moment of breaking the fast (iftar) in Ura, how they met the night of Qadr, celebrated Eid al-Adha and gave alms, like nowhere else, solemnly and in a special way.

**Iftar.** During Lent, having had nothing to eat since morning, eating after sunset is called breaking the fast, or iftar in Arabic. Whatever you say, religious traditions are not so strongly observed by the Arabs, the founders of Islam, or in southern Bukhara. It is more difficult for us, the Tatars. Because during Lent we have the longest day in Kazan, Bolgar, Tobolsk, Tyumen and more northern places: a day lasts for 20 - 18 hours; however, the Tatars are sincere, or, as Maksim Gorky noted, they are a very hardworking and very patient people. Especially if it is necessary to carry out a task given from above, such as the Uraza fasting; as believing people, they are ready to perform this task. Perhaps, during the month of Ramadan, the Tatars fast in the hope that other sufferings would be easier, which is probably why the Tatars consider it a particularly pious deed, while breaking the fast, to treat to nice things the people who fasted all day. These iftar traditions were also performed in especially grand way by the manufacturers of the town of Nizhnyaya Ura. The factory owners were master-hands of arranging celebrations and feasts during the Uraza fasting. Like this:

“During the Uraza, lanterns were lit in front of the mosques, and the Koran hatem[11] took place inside the mosque. Shakirds walked in rows on the way to iftar, the start of the row in the mosque, its end– at the gates of the rich man. In front of the mosque, at the gates, there were carts or winter sledges harnessed in the town, they took teachers, imams and muezzins for a ride and drove past the rows of shakirds...” [11]. In other words, scholars, madrasah teachers and shakirds received special attention and were generously rewarded.

“Big iftars (a dinner party of breaking the fast) were held by 11–12 rich people: one day – exclusively for scholars, the second day – for shakirds, the third or the fourth day – for the villagers. Iftars for some were specially held in large thirty-arshin pavilions. Tables were laid there, there were 10–15 people at each table. There was also a large cauldron in which oil was boiling, its large portions (ladles of it) were poured into porridge and pies [11].

As you know, only national dishes were served there, no alcoholic drinks were consumed at such events.

It happened like this in the village: “As soon as it became known that iftar was planned at one of the rich men’s houses on a certain day, all the poor men, women and children, widows, gathered at the rich man’s gate with their plates. The whole street or lane was packed with people. Serving men and women distributed meat and porridge cooked in large pots. [11]. (These events were reminiscent of subbotniks in the ancient Bulgar Khanate, when after the sowing campaign all the people were treated to a nice meal, and of the general feast for soldiers during the war. Also, we see that men were together with women there. Thus, light industry, the collectivism of factories and the change in the way labor was conducted prevented the women of Nizhnyaya Ura from living locked up in their households, although they were purely Tatars and lived under the teachings of the Bukhara scholars. Such a state of things and a desire to protect women from male oppression is read in the reports of Fathulla akhun from Ura, written to the leadership of the muftiate [27, pp. 13–72].

**Night of Qadr**. “The whole district from 20 to 30 versts was in turmoil, all the streets and fields were full of people. If you went out onto the road, there were rows of people all the way. All these people were divided into groups, admitted into the courtyard in turn; the gates were locked, there were guards inside and clerks came from outside and handed out alms in turn, inside the guards kept order and let the people out. The guards outside followed them. Then another group was permitted to come in and a third one. (This custom does not seem to be found elsewhere.) [11]

It was like Christmas in the past, a gift from Santa Claus, a tradition of giving gifts and treats.

[11] Hatem – to read the entire Quran and make a dedication. The Quran was read alternately by a kary (reader of the Quran) and pish-kadams (assistants of ishan) throughout the whole Uraza. *(Note by Naki Isanbet)*

Such way of spending the night of Qadr does not occur in this way in other parts.

**Eid al-Adha (The Feast of Sacrifice).** In this town, the celebration of Kurban Bayram acquired the color of glorifying one's wealth.

Sharifzhan Gabdullovich wrote: "Kurban is also important. Countless sheep and rams, about thirty cows, and even an ostrich were sacrificed" [11]. (The delivery of ostriches and camels from Siberia to Ura was due to the constant caravan trade in those days from Central Asia to Orenburg-Troitsk. Bringing a camel to Ura and sacrificing it on Eid al-Adha was meant to glorify wealth and success).

**Distribution of Zakyat.** Zakyat is the distribution of one fortieth of your capital among the poor, the needy once a year; so, if you have a capital of 200 thousand rubles, you must give five thousand rubles to those needy. This religious prescription for every Muslim is a tax. This means that this tax first of all concerned the rich of Ura. The rich of Ura, who liked to show themselves to the people as pious, religious people, could not refuse to distribute zakyat in any way. The akhun, the ishan and other learned clerics told the believers to observe zakyat.

In Ura, there were rich people whose capital was one hundred thousand (in gold!) and even more, about 10–12 people, among them were millionaires, therefore, to be honest, the rich people of Ura had to distribute zakyat amounting to 50–60 thousand rubles. That's a lot for the price of gold. And the rich of Ura performed it, whether they wanted it or not, be that as it may, they saved appearances. They and the mullahs determined the amount to be paid as zakyat, and transferred goods equal to this amount under their control. As a rule, goods from the store were donated as zakyat.

At first glance, everything seems to be fine. However, how was it done in reality? How were the products distributed? As you know, the Russian tsarist government did not interfere in the religious activities of the Tatars, there were no controllers or auditors. And there was no bookkeeping either. But there was a procedure for distributing zakyat. It worked in this way: the mullahs took this matter under their control, conducted it according to the ancient Sharia, according to oaths. For the happiness of the rich, the mullahs were from their parish, i.e. they were appointed mullahs to the parish by the same rich men. Thus, usually, as the rich man wanted, the mullah would do so. In general, the mullah did not know and could not know the nuances of the trade. Moreover, this case was not a law for the Russian state, it was not a formal tax. If the rich man gave zakyat, then it was distributed as his religious duty. In short, here in tsarist Russia, for the Tatars, who did not have their own state, zakyat, if it really was a tax, sank to the level of a simple voluntary alms. For alms it was impossible to approve the norm. In addition, it had to be given in money, and the merchants exchanged it for goods. There were no quality or brand requirements. It was then that the machinations, called the cunning of Sharigat, were employed. As zakyat, the rich gave spoiled goods or goods that had got damp in the cellars, or were beginning to rot, or it was sugar smelling of kerosene, or something of the sort– they didn't look a gift horse in the mouth, they gave you zakyat for free! Read the prayer and take it away!.. In short, under the guise of giving zakyat, there were obviously cases of the store spring cleaning.

However, if a rich man, being a very pious person, gave zakyat very honestly and according to the rules, it could not be said that he was a loser. Since the fame of the rich man, the fact that he was very pious and "an honest, fair trader" contributed to the sales of his goods. His distribution of zakyat in a grand, generous manner advertised his company, his goods, spread the fame of an honest person about him, thus he very quickly made up for the cost of zakyat fivefold.

If you ask how the distribution of zakyat was carried out in this manufacturing town, it would be very interesting to get acquainted with this process. This, of course, was carried out in a grand manner, involving the whole town, as one of the customs peculiar to Ura. For example, as Sharifzhan Gabdullovich, a witness of this, wrote about this: "The aforementioned 10-12 rich people reported about their zakyat and determined the amount of zakyat with the mullah-muetzin; the next day a written prescription came to the mudarris (the main teacher in the madrasah) through the clerk. It was written there: "Khazrat, write down the number of shakirds in the madrasah and their positions"; Khazrat sent this paper to Kazy[12]. Kazy, having made a list, sent it to the rich man. The rich man, through the clerk, sent a paper to the madrasah where he wrote how many shakirds and of what rank were to come. Shakirds came to the rich man and received a piece of chintz, a piece of basma, a rainbow fabric for a chapan, seven arshins of

[12] *Kazy* – the one responsible for order and silence in the bedrooms of the madrasah, a warden *(Note by Naki Isanbet).*

calico[13], one tile of tea and a paper for the second rank of shakirds. They came and got a little less than the first ones. The third, fourth and fifth groups received even less, in the end the saryfkhans[14] got one bar of tea, and the torkekhans (or the youngest shakirds who studied in the primary class in their native language) received half a bar of tea" [11]. It is interesting to mention here that primary school students were called torkekhan. As in other Tatar madrasah schools, in the elementary grades of the Ura madrasah, they were first taught the alphabet, reading and writing in their native language. Senior students, depending on the discipline, were called saryfkhan, mokhtasarkhan, and students studying in their native language were called torkekhan. (The word "khan" was not used in its meaning in the Tatar language, but came from Farsi "khon" – pupil, student).

And, as follows from this entry, in Ura, zakyat was not distributed according to how shakirds were needy, whether they were orphans or poor people, but was distributed according to what class they were in and it increased in accordance with their seniority. At one time, the manufacturers of Ura attached great importance to education and training, sponsored large madrasahs from their own pockets, and zakyat was first distributed to shakirds, increasing from class to class, they stimulated interest in learning. This fact deserves attention from the point of view of the attitude of the bourgeoisie to education and the revival of local traditions. Since the tsarist government did not allocate funds for the maintenance of Tatar schools, our education, left unattended, could exist only thanks to donations or help of some generous rich patrons.

"On the third, fourth, fifth days, zakyat was distributed to the villagers and some ordinary people" [11]. (There, the mullah, the muezzins, although they were appointed by the tsarist government, did not receive a salary, they lived only on donations, and therefore they were given zakyat).

In addition, those in need: sick old people, the poor were given chintz, tea and sugar. The grand distribution of zakyat was characteristic not only of the rich in Ura, as you know, the rich of Kazan and Orenburg also loved to boast of these donations at one time. Therefore, we dwelled in more detail on these events of our story.

**Results**

Ura, being a manufacturing town, in which Tatar life was in full swing, aroused interest with its orders. That's what it was like.

Starting from the middle of the 19th century, Sharifzhan Gabdullovich, who studied in Ura, described the town of Ura using magnificent, noble images: "Things are big here. Rich. Large buildings. Amazingly beautiful gardens. Manufacturers. Decorated with calico, chintz and calico factories. At least 7 - 8 factories. Blue, green, black calico, various calico fabrics are hung out to dry along the river. You can't but fall in love with the place. The sounds of the factory owners resound throughout the town. In the evening, in 9 – 10 houses, they beat a cast-iron pot, and here and there the voices of the guards are heard..." [11].

Then he proceeds to describe the fact that Ura was a town of prominent scholars, a town with a madrasah: "Ura is the capital of scholars and intellectuals. Schools and madrasahs are full of shakirds, from different villages, full of Tatars, Bashkirs, Mishars, there are at least 200 – 250 of them. A stone mosque, a wooden mosque... "[11] .

For a small town of two parishes, these are not minor facts, as Sharifzhan Gabdullovich wrote, in Ura the affairs and wealth of the factories were really great.

Mardzhani noted the fact that Ura was rich, there were prominent akhuns and ishans, that its mosque was a unifying place for the mosques of neighboring villages, on Fridays they gathered there for prayer. It should be noted that when after the capture of Kazan, the Tatars were exiled to the northern forests, the Tatar education center in Kazan was destroyed and Ura took the role of this center in the 16th–17th centuries.

Obviously, just the fact that Ura was called a town in the bayt does not make it a town. Looking at the village of Ura now, one asks a question: once upon a time did it really use to be a town? After all, it might have been called a town only for the sake of a beautiful word or as a mockery at the fact that it looked like a town!

Indeed, now Ura is one among other similar villages. However, upon closer examination, it did not use to be like these villages at all.

[13] The fabrics mentioned here – chintz, basma, iridescent fabric, kumach – were produced by the manufacturers of Ura. Indicated in the notes *(Note by Naki Isanbet)*.

[14] *Saryfkhan* – a shakird, studying the morphology of the Arabic language, in other words, a student at the initial stage of Arabic language grammar. The word "khan" here it is not in its meaning in the Tatar "khan", but in the meaning – "student" *(Note by Naki Isanbet).*

**References**

1. Isənbət, N. *1872 elgy Orynyң kichke kyreneshe nichek tasvir itelə?* [How Shall I Describe the 1872 Night View of Ura]. N. Isənbətneң shəkhsi arkhivy. (In Tatar)
2. Isənbət N. *Kaityr yul* [The Way Back]. N. Isənbət shəkhsi arkhivy. Kul"yazma. Mashinkada basylgan. 7 p. (In Tatar)
3. Isənbət N. *Ory avylynyң dvoryannary* [The Nobility of the Village of Ura]. Kul"yazma. Mashinkada basylgan. 3 p. (In Tatar)
4. Isanbet, N. (1982). *Ory Akkan* [Ura Flooded]. Rukopis' Naki Isanbet. Pechatnyi variant, 70 p. (In Tatar)
5. *Nəkyi Isənbət* (2021) [Naki Isanbet]. Təz. M. M. Khabutdinova. 736 p. Kazan, "Zhyen" fondy nəshr. (In Tatar)
6. *Ory akkan bəete* [Ura Flooded Bayt]. Zəki Gafarov kүchergən nəskhəse (Mavarbashy (Alshaika) avyly, Mariistan). Nəkyi Isənbətneң shəkhsi arkhivy. Kul''yazma. (In Tatar)
7. *Ory akkan bəete* [Ura Flooded Bayt]. (Kərimə Kurmasheva nəskhəse). Nəkyi Isənbətneң shəkhsi arkhivy. Kul''yazma. (In Tatar)
8. *Ory akkan bəete* [Ura Flooded Bayt]. Səet Vakhidi nəskhəse. Nəkyi Isənbətneң shəkhsi arkhivy. Kul''yazma. (In Tatar)
9. *Ory akkan bəete* [Ura Flooded Bayt]. Nəkyi Isənbətneң nəskhəse. Nəkyi Isənbətneң shəkhsi arkhivy. Kul''yazma. (In Tatar)
10. *Məkhəmmətshərif Gabderəshit uly "Кәҗә бәете"* [Mukhammatsharif Gabderashitovich "Kazha baete" ("The Goat Bayt")]. Nəkyi Isənbətneң shəkhsi arkhivy. Kul''yazma. (In Tatar)
11. *Shərifҗan Gabdulla ugyly kul''yazma dəftəre* [A Manuscript Notebook of Sharifjan Gabdullah's Son]. Nəkyi Isənbətneң shəkhsi arkhivy. Kul''yazma. (In Tatar)
12. *Kalendar' 1900 elga* (1899) [The Calendar of 1900]. Təz. Sh. Rəkhmətullin. Kazan, 38 p. (In Tatar)
13. Mardzhani, Sh. (1900). *Mostafadel-akhbar fi akhvali Kazan va Bolgar* [Stories about the Events in Kazan and Bolgar]. Vol. II. 368 p. Kazan, Tipo-litografia Imperatorskogo universiteta. (In Tatar)
14. *Ory beyete* (2021) [The Ura Bayt]. Milli Madani Mirasybyz. Mari El Tatarlary. Barange. Pp. 79–82. Kazan. (In Tatar)
15. Salikhov, R. R. (2015). *Sluzhilaya Ura: rozhdenie tatarskogo kapitalizma* [Serving Ura: The Birthplace of Tatar Capitalism]. 280 p. Kazan, Institut istorii im.Sh. Mardzhani AN RT. (In Russian)
16. Badig, Kh. (1919). *Khalyk adabiyaty: Baetlar* [Folk Literature. Bayts]. 2 ed. 127 p. Kazan, 6 gos. tip. (In Tatar)
17. Tolymbay, G. (1935). *Baetlar*: *Revolyutsiyaga kadarlar* [Bayts: Before Revolution]. 151 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)
18. *Tatar khalyk izhaty* (1951) [Tatar Folklore]. Təz. G. Bashirov, A.Shamov, Kh. Yarmi and Kh. Usmanov. 523 p. Kazan, Tatknogoizdat. (In Tatar)
19. Yarmi, Kh. (1960). *Baetlar* [Bayts]. 388 p. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)
20. *Tatar eposy. Baetlar* (2001) [Tatar Epos. Bayts]. 510 p. Kazan, Rannur nashr. (In Tatar)
21. TÜRKIYE DIŞINDAKI TÜRK EDEBIYATLARİ ANTOLOJISI (2001) [ANTHOLOGY OF TURKIC LITERATURES OUTSIDE TURKEY]. 17. cilt. Tatar Edebiyati I. Ankara: Kültür Bakanlığı Yayınları. Hazırlayan M. Zekiev, F. Urmançiev. (In Turkish)
22. *Or karyasen su basty* (1983) [Ura Village Washed Away]. Tatar khalyk izhaty. Baetlar. Pp. 27–28, 292–293. Kazan, Tatar. kit. nashr. (In Tatar)
23. *Tatarskoe narodnoe tvorchestvo* (2022) [Tatar Folklore]. V 15 tomakh.T. 9. Baity. . 479 p. Kazan, Tat. kn. izd-vo. (In Russian)
24. Fakhretdin, R. (2006). *Asar* [Asar]. Vol. 1. 303 p. Kazan, Rukhiyat. (In Tatar)
25. Fakhretdin, R. (2006). *Asar* [Asar]. Vol. 2. 359 p. Kazan, Rukhiyat. (In Tatar)
26. *Shahri Kazana sayakhat* (1902) [A Journey to the City of Kazan] Kazan. (In Tatar)
27. Fakhretdin, R. (1904). Asar [Asar]. Vol. 2. 93 p. Orenburg. (In Tatar)

# КАЗАН АРТЫНА БЕРЕНЧЕ СӘЯХӘТЕМ: «ОРЫ АККАН»[1]

**Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәт,**
Казан,
mileuscha@mail.ru.

Мәкаләдә энциклопедист галим Нәкый Исәнбәтнең фольклор экспедицияләренә караган тарихи материаллары системага салынды. Фольклорчы 1938 елда ТАССРның Әтнә һәм Кызыл Юл районнарында методист булып эшләгәндә, җәяүле экспедицияләргә чыга. Мәкаләдә анализ

[1] Мәшһүр татар энциклопедист галименең архивында эшләгәндә, без Казан арты татар фабрикантлары тарихына караган һәм моңа кадәр бер тапкыр да басылмаган «Оры аккан» хезмәтләренә тап булдык [1], [2], [3], [4]. Материал Нәкый Исәнбәтнең кульязмаларыннан журнал таләпләренә мөхәррир М.М. Хәбетдинова тарафыннан яраклаштырылды.

өчен төрле чыганаклар – «Оры аккан» бәете, халык истәлекләре, риваятьләр һ.б. кулланылды. Бәетнең фольклорчы тарафыннан төзелгән җыелма тексты беренче тапкыр басылып чыга. Татар чыганакларын анализлау нигезендә Түбән Оры фабрикантларының тормышы реконструкцияләнә.

**Төп төшенчәләр:** Татарлар, этнография, Нәкый Исәнбәт, татар фабрикантлары, Түбән Оры

## Кереш сүз

Оры шәһәре исемен күргәч, хәзерге кайбер күп белемле укучы шунда ук кайтарып шундый бер сорау бирүе бар:

– Оры шәһәре? Андый исемле шәһәр бездә бармыни, булганмыни? Бер дә ишетелгәне-ниткәне юк. Оры, Оры... Андый бер исемле шәһәр тарихта да, карталарда да күзгә күренми шикелле, – дип, ихтимал, аны юкка ук чыгарып ташлар.

«Оры аккан» исемле бәеттә ул «шәһәр» дип атала. Әмма аның дөрес кенә исемен ничек дип укырга? Гарәп хәрефе белән язылышында аны дүрт төрле итеп укып була: Урый, Ура, Оры, Өре...

## Фәнни хезмәтнең материалы һәм методлары

Оры аккан хакында түбәндә язылган сүзләр шулай хосусый очрашулардан җыеп алынган материаллардан, шулай ук кулымда җыелган бәетләрдән һәм элекке фабрикантлар Орысы хакында кайбер риваять-хәбәрләр һәм җыйнаганым кайбер язма документаль белешмәләрдән гыйбарәт. Суга аккан татар шәһәре турында «Оры аккан» бәете төрле нөсхәләре [4, 44–50], [6], [7], [8], [9], [10], легендасы [4, 39-40 б.], Шәрифҗан Габдулла углы хатирәләре [11] фәнни мәкаләнең өйрәнү материалы һәм чыганаклары булып тора. Хезмәттә тасвирлама, чагыштырма, чагыштырма-тарихи, фәнни чыганаклар белән эшләү, анализ һәм гомумиләштерү традицион методлары кулланылды.

## Фикер алышу

Мин бу юлларны язган 1938 елда Оры акканга 121 ел тулды. Тулды да үтеп тә китте. 1938 елда миңа Казан арты Әтнә, Кызыл юл районнарында мәктәпләр тикшереп йөргәндә, Түбән Оры дигән бер авылга барып чыгарга туры килде. Сорый калдым:

– «Оры аккан» диләр, әллә ул шушы буламы?

– Шушы, – диләр.

Билгеле инде, мәктәп эшләремнән бушану белән мин шул хакта сораша башлыйм.

Шәһәр тикле шәһәр аккан булгач, ул хакта календарь һәм тарихи китапларыбызда, әлбәттә, белешмәләр бирелгән булыр. Каюм Насыйридан карыйм, бар, ләкин Орыны, әлеге дүрт төрле итеп укыла торган Орыны, су баскан булуы турында кыска бер хәбәр генә. Календарьчы Шиһап Рәхмәтуллинда да (1900 ел) Орыны су басу турында кыска рәвештәге мәгълүм бер легенда гына [12]. Болардан соң Оры турындагы хәбәр һәм вакыйгаларның киңрәген Шиһап Мәрҗанидән килеп табабыз. Аңарда үзенең тарихы, андагы бер фамилиянең шәҗәрәсе һәм су басу вакыйгасы турында да шактый кызыклы мәгълүматлар бирелә. Мәгәр, Мәрҗани аның исемен (Ур, Үр, Ор, Өр) дип кенә яза, һәм, күрәсез, моны да шулай ук баягыча дүрт төрле укып була. Аннары Мәрҗани аны «шәһәр» дип атамый, «къәрйә» – ягъни авыл дип кенә йөртә. Кыскасы, мин эзләгән сорауларга Мәрҗанидә[2] дә турыдан-туры өзеп кенә җаваплар юк, киресенчә, хәбәрләр катлаулана барган саен ачыкланмаган яңа мәсьәләләр арта гына бара [13, 22 б.].

Болардан соң мин игътибарымны фольклорчыларыбызга юнәлтәм, әйе, әйе, алар бу бәетнең төрле кульязма нөсхәләрен, әлбәттә, тапкан, җыентыкларында да бастырган булырга тиешләр. Вакыйгасы һәм әһәмияте хакында аларда, әлбәттә, кайбер белешмә мәгълүматлар бирелгән булыр дип, аларны карый башлыйм[3].

---

[2] Ш. Мәрҗани Оры авылында су басу фаҗигасе вакытында 82 кеше һәлак булганы турында яза. Галим Бәрәңге төбәгеннән булган мулла Мөхәммәдшәриф ахун бине Габдеррәшид бине Йосыф бине Кадер бине Бикмөхәммәд шагыйрь булуын, аның үз кулы белән язылган «Оры аккан бәете», «Кәҗә бәете», «Чәй бәете», «Кече хатын» кебек шигъри, халык арасында таралган әсәрләре барлыгы турында әйтә [13, 22 б.]. М. Әхмәтҗанов «Якутлар табыладыр вакыт белән...» хезмәтендә 2001 елда «Аккан Оры бәете»нең кыскартылган вариантының 1840 елларда төзелгән шигъри әсәрләрдән тора торган җыентыкта табылуы турында яза. 2012 елда галим Оры бәетенең тулы вариантын укучыларга тәкъдим итә [14, 79–81 б.]. – *М.Х.*

[3] 2015 елда Р.Р. Салиховның «Служилая Ора: рождение татарского капитализма» исемле монографиясе басылып чыкты [15, 43-45 б.]. Автор китабына «Казанские ведомости» газетасында 1817 елда чыккан мәкаләне керткән. Царевококшайск җирле суд

Менә кулымда бәетләр китабы. Хуҗа Бәдигъ җыеп бастырган (1919, икенче басма) [16]. Ул инде Казан артын күп гизгән, шунда туып үскән. Үзе ул патша заманында Казанның мәшһүр «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыткан, миңа да мөгаллим булган кеше. Телче һәм зур фольклорчыбыз. Ул инде бу бәетне, әлбәттә, күргән, кирәк булса, Орының үзендә дә булган булыр. Китабын ашыгып кулыма алам. Карыйм – ләкин анда да бу бәет юк. Бөтенләй дә кермәгән. Ни өчен юк? Димәк, ул аны игътибарга алырлык әһәмиятле бәет дип тапмаган? Яки башка бер сәбәп?

Гумәр Толымбайский «Оры аккан»ны бәетләр китабына кертерлек әһәмиятле нәрсә итеп тапмаган [17]. Кертсә дә, ТАППның ул замандагы вульгар социологизм кагыйдәләренә берәр яктан сыймаган өчен төшерелгән. Аннан соң менә 40 нчы, 50 нче еллар китә... Тел-әдәбият институты чыгарган халык иҗаты китаплары [18]. Алардан соң 1960 елда АНның Казан филиалы чыгарган калын «Бәетләр» китабы. [19] Ләкин «Оры аккан» аларда да басылмаган.

Кыскасы, җирле әдәби, мәдәни мирасыбызны барлау һәм саклау хисе, гражданлык хисе миңа тынычлык бирми иде. Заман башка, һәм ул бик кызу темп белән бара, эзләр һәм мирасларның аның саен тизрәк югалу куркынычы алга баса... Орының кайчандыр туфан баскан ул авылмы-шәһәрменең үзен барып күрергә хыяллана башладым. Сорашып белдем, үзе ерак та түгел, Казаннан 70 кенә чакрым җир икән. Инде ул элекке язмаларны яңалифтән (латиннан) бу хәрефләргә күчергәнем 1982 елда ул вакыйгага, ул бәетләргә 165 ел тулды. Бу хакта Орылар берни дә әйтмәгән кебек, фольклорчы тарихчыларыбыз да берни дәшми үтте. Шулай тарих. Шулай безнең күмелә барган эзләр[4]...

Түбән Орыны су басу вакыйгасы Коръән-Инҗилләрдәге кебек алай ук бөтен дөнья туфаны кыйссасы булып китмәсә дә, күрәсез, фольклор өчен монда да җитәрлек азык бар. Аның да үз легендасы барлыкка килгән.

*Оры аккан легендасы*

Болай дип сөйлиләр.

Оры фабриканты Мәхмүт байга бер теләнче бабай кереп, садака сораган. Биргәч-алгач, бабай тәһарәт төзәргә су сораган. Баскыч төбендә комган, ишек алдында арбада мичкә белән су тора икән.

– Әнә, үзең агыз да ал, – дип әйтергә генә бит югыйсә, ә юк, Мәхмүт байның бирәсе килмәгән. Тасраеп:

– Әнә, пакьләним дисәң, елгада су күп. Монда сиңа түгел, әле үзебезгә дә мәшәкать

донесениесенә таянып, мәкаләнең авторы Оры авылында су баскан көнне 15 кеше батып үлгәне, 12 кеше хәбәрсез югалганы турында яза. Авылның хуҗалыгына (йортлар, фабрикалар, кибетләр, он тарту тегермәннәре) килгән зыянны 118,394 сум дип билгели. Көчле яңгыр аркасында авыл уртасында аккан инешнең суы, ярты сәгать эчендә 5 метр (7 аршин) биеклеккә күтәрелгән булган. Су ташкыны шундый көчле булуы аркасында, кешеләрне, мал-туарларны, йорт-кураларны авылдан 20 чакрымераклыкка тараткан. – *М.Х.* Р. Салихов, Оры авылы байларының Император исеменә язылган үтенечләренә нигезләнеп, сатучы Мөхәммәт Хуҗасәитовның 45 мең сум зыян күрүен билгеләп китә, ә аның абыйсы Муса Хуҗасәитовның хуҗалыгына 140 мең сум зыян килгәне турында яза [15, 43 б.]. – *М.Х.*

[4] 1983 елда «Татар халык иҗаты. Бәетләр» китабында «Ор карьясен су басты» исемле бәет басылып чыга. Текстның искәрмәсендә шундый мәгълүмат бар: «Ор һәм Оры, карья (авыл) һәм шәһәр дип йөртелә». Татарстанның хәзерге Арча районындагы Түбән һәм Югары Оры авыллары. Р. Фәхретдин үзенең «Асар»ында (2 җөзә, 55–56 битләр) Оры карьясенең кешеләрен атап үтә. «Оры аккан» бәете 1817 елда Оры авылында зур ташкын булып, күп халык өйләре, гаиләләре, каралты-куралары белән суда агып китү вакыйгасына багышлап чыгарылган. Бәет авторы Казанның бер мәхәлләсендә һәм Бәрәңге ягы Портянур авылында (хәзерге Мари АССР) ахун булып торган Мөхәммәтшәриф Рәшит улы Юсупов булырга тиеш» [20, 27–28, 292–293 б.]. 2001 елда шул ук вариант искәрмәләр белән «Татар эпосы. Бәетләр» китабында басылып чыга [21, 64–65 б.]. Шул ук елда Әнкарада «Төрки әдәбиятлар антологиясе»ндә дөнья күрә [22, 360–361 б.]. 2012 елда «Оры бәете» «Милли мәдәни мирасыбыз. Мари Эл татарлары. Бәрәңге» китабында чыга. [14, 66–68 б.]. Бу бәет искәрмәләр белән рус телендәге «Татарское народное творчество» 15 томлыгының «Бәетләр» исемле 9 нчы томында 2022 елда басылды [23, 51–52; 400–401 б.]. ТӘһСИ фондында бәетнең вариантлары 1941 елдан саклана (информант – Шәкүр Сөләйманов (1861 елгы), Кече Ярамай авылы, Чүпрәле районы, ТАССР); бер вариант – М.Гали фондында (датасыз), Н.Ибраһимов 1970 елда Арча районында язып алган вариант та бар. Бәетнең ике варианты З.Максудова архивында саклана. Ул аны Давыд Шаһиәхмәт улының 1819 елдагы җыентыгыннан күчереп алганын теркәп куйган. [20, 27–28, 292–293 б.]. Бу текст Н. Исәнбәтнең 4 нче «Габит» исемле өлеше белән аваздаш. – *М.Х.*

белән мичкәләп кенә алып менәбез, төш тә юын, – дигән.

Мәхмүт бай теләнчегә су бирмәгән...

Күңеле сынык карт моңа эченнән бик рәнҗегән, башын күтәреп, алдына караган да:

– Алла сиңа мәшәкатьсез генә су бирсен! – дигән.

Дигән дә чыгып киткән, ди.

Белмим – шул карт Хозыр Ильяс булганмы, я булмаса, рәнҗүе карусыз калмый торган болай бер изге кешеме, ул китеп, ярты сәгать тә үтмәгән, нәкъ икенде вакытында, тын гына торганда, менә бер заман җәйге көнбатыштан кечерәк кенә бер болыт кисәге чыгып, Оры өстенә килә башлаган, халык аңа башта игътибар да итмәгән инде. Болыт дисәң болыт. Беткәнмени! Менә шул, килеп тә җиткән, кинәт кенә кабарып, кап-кара булып, көнне каплап, шәһәр өстенә ауган. Ауган-төшкән дә, менә бер бик каты каһәр белән шатырдатып, күк күкрәп, яшен атып җибәрмәсенме?.. Шуннан бу: «Әһә... әле сиңа су кызганыч булды, әнә елгага төшеп юынмы? Менә сиңа, алайса, төшмичә генә юын, коен!» – тотынган яварга, бервакыт, минсиңайтим, тотынган яварга! Бертуктамый ата да ата. Шатырдаган боз да су, тын алырга да юк, туфан! Шуннан ни, үзең күрәсең, әлеге хәл. Оры аккан!

Легенда әнә шуннан гыйбарәт.

Инде бу легенда һәм ил авызындагы хәбәрләрнең гадәттәге фольклор кабыгын әрчеп карасак, эшнең чынына килгәндә, шәһәр агарлык зур ташу бер Түбән Орыда яуган каты яңгыр аркасында гына булмаган булса кирәк, чөнки әлеге хәбәргә караганда, ишанның бер өе өзелеп агып китеп, икенчесе Мүсәкәй елгасыннан төбе-тамыры белән кубып, агып килгән бик зур чыршыга терелгәне өчен генә акмый калуы үзе үк югары як Мари урманнарында яңгырларның тагын да катырак булып, ташуның аннан ук куәтле килүен күрсәтә. Шулай итеп, ике елга тамагында утырган Түбән Оры берьюлы ике ташу һәм өстән кинәт каты яңгыр килеп басу аркасында аккан.

Әнә хәзер дә аның бәетләре төрле кульязмаларда минем алдымда яталар. Менә аның Марийстандагы Мазарбашы (Алашайка) авылының Зәки Гафаров күчергән нөсхәсе [6]. Менә Кәримә Кормашева[5] [7], Сәет Вахиди [8] нөсхәләре. Яки үзем тапкан бәет дәфтәрләрендәге күчермәләр [9]. Хәтта аның мәшһүр Кәҗә бәете авторының[6] Йосыф китабы көенә язылган «имди»ле бер нөсхәсе дә [10] кулымда һәм башкалар. Нәтиҗәдә, Оры гына акмаган монда, аның безгә мирас булып калган бәетләре дә безнең гасыр туфаннары астында читкә кагылып, алар да кайбер әби-бабайларның букчасында я минем шикелле сирәк картларның хәрефләре җуела барган архив кәгазьләре арасында очраклы рәвештә генә сакланып калган.

Бәет шактый озын. Вариантларында, әлбәттә, кайбер аермалар, башкалыклар, үзенчәлекләр бар. Кайберләрендә васыять сүзләре озын һәм, гомумән, кабатлаулар бар. Күрәсең, үлем фаҗигаләре зур һәм күп кешеләр башыннан үткәнгә, башта бер генә бәет чыкмыйча, берничәләп чыккан, бара-бара, алар кулдан кулга күерелә-күчерелә, үзләреннән-үзләре бергә кушылып киткән булса кирәк.

Кыскасы, бәетне укучылар алдына куйганда, мин андагы кайбер кабатлауларны кыскартып, аерым кеше исеменә караган юлларны үз тирәсенә җыеп, әһәмиятлерәк күренгән юлларын сайлап алып, монда күчердем.

Бәет түбәндәге шәкел ала.

*Оры аккан бәете*

1
Юлны юлга тезгәннәр,
Уртасыннан өзгәннәр,
Оры шәһәре хакында
Бу бәетне төзгәннәр.
Казан дигән илләрдә,
Оры дигән җирләрдә,
Алты аршин су булган
Уйсурак җирләрдә.
Олуг җомга көн иде,
Байлар мәчеттә иде,
– Атлар агып китә! – дип,
Атбашчылар кычкырды.
Бозлар сукты, туфан купты,
Өйләр ага башлады,
Моны күргән адәмнәрнең
Хәйран калды башлары.
2
*Байлар хәле*
Тау өстендә Муса бай,
Тау астында Мәхмүт бай,
Сәфәр киткән Муса байга
Ярдәм бирсен бер Ходай,
Муса киткән Мәкәрҗәгә
Кызыл маллар алмага,
Муса бай кайтып җиткәнче,

[5] Мари республикасы Мазар башы авылыннан. Мөхәммәт Кормашев кулы белән күчерелгән бәет нөсхәсеннән. 1927 ел. (Нәкый Исәнбәт искәрмәсе).

[6] Мөхәммәтшәриф Габдерәшит улы (1834 елда үлгән).

Өйләре акты дәрьяга.
Оры шәһәре агып бара,
Амбар тулы маллары,
Аны күргән байларның
Чак чыкмады җаннары.

Мәхмүт байның фабригы
Агып барган Колларга[7],
Эчендәге маллары
Очыраган бурларга.
Мәхмүт байның чарлагы
Агып барган Колларга,
Дошманнары шат булган
Агып киткән малларга.

Мәхмүт байның чарлагында
Агып киткән ун кеше.
Колларга барып җиткәнче
Таралмаган бер төше.
Мәхмүт байның йортлары
Агып бара дөңгердәп,
Колларга барып җиткәндә
Ишелеп төшкән гөмбердәп.
Мәхмүт байның чарлагы
Бар да мамык мал икән,
Су эчендә җан бирмәк
Бигрәк мөшкел хәл икән.
Мәхмүт байның йортлары
Вәйран булды җөмләсе,
Эчендәге ир вә хатын –
Шәһит булды һәммәсе.

Мәхмүт барган Колларга
Чарлак эчен карарга;
Исе китеп еглаган
Агып барган малларга.
Мәхмүт байның йортлары
Уйсу җиргә салгандыр;
Әле дә шөкер Ходайга
Үзе исән калгандыр.

3

*Габделхалыйк мулла хәле*

Габделхалыйк мулла кеше
Агып бара су белән;
Тәрәзәдән башын тыгып
Тәкбир әйтә тел белән.
И элмәлек, элмәлек,
Элмәлеккә кермәдек;
Сулар белән агып киттек,
Үләсебезне белмәдек.

И хәләлем хатыным,
Тәкъдир җитте, үттек без,
Дөнья артындин йөри торгач,
Ахирәткә җиттек без.
Мулла хатыны әйтәдер:
– Ике угылым күрсәмче;
Бу галәмәтне күргәнче,
Аз элгәре үлсәмче!

(Габделхалыйк мулланың
Өйләре дә калмады,
Мулла хатыны абыстайның
Гәүдәсе табылмады.
Ул мулланың кызын да
Тазларга[8] илтеп күмделәр
Мулла кызы икәнен
Үлгәннән соң белделәр.)

4

*Габит*

Габит чәчен алдырган,
Түбә чәчен калдырган,
Габит мескенне сорасагыз –
Суда җанын алдырган.
Түбәтәен киядер,
Киядер дә саладыр,
Оры дигән җирләрдә
Сөйгән ярым каладыр.

Сулар гөрләп агадыр,
Габит агып барадыр;
– Абзый мине алсана! – дип,
Тилмереп еглап барадыр.
Казлар оча еракка,
Куәт бирсен канатка,
Габит белән Ибраһим
Китте Коллар зиратка.

– И хәләлем Хәдичә,
Васыятем шул сиңа:
Ятимнәрне ташласагыз,
Бәхиллегем юк сиңа.
Коллар иленә барыгыз,
Каберем сорап табыгыз,
Казганып җыйган малларны
Хәер-ихсан кылыгыз.

Безнең авылга барыгыз,
Сәлам, диегез муллага,
Кул күтәреп дога кылсын
Безнең өчен Аллага.

5

*Орыга бүрек алырга барган җирдән*

– И әткәем, әткәем,
Мин Орыга бараем,
Азрак байдан акча сорап,
Башыма бүрек алаем.

– Барсаң, угылым, барырсың,
Сәүгән бүркең алырсың;
Анда сиңа тәкъдир җитсә,
Безне күрми калырсың...

– И әткәем, сән үзең
Нидән әйттең бу сүзең?
Суга агып киткән чакта

[7] *Коллар* – авыл исеме. *(Нәкый Исәнбәт искәрмәсе.)*

[8] *Тазлар* – авыл исеме. (*Нәкый Исәнбәт искәрмәсе.*)

Ачалмадым һич күзем...
И әнкәем Гөлзифа,
Ак сөтеңне хәләл ит,
Хезмәтеңне итә алмадым,
Күңелеңнән бәхил ит.
Быел чәчкән тарымны,
Әнкәй, барып урсана,
Бән суларга агып киттем,
Әнкәй, каберем сорасана![9]
5.
Ахшам вакыты булганда,
Күп кешеләр үттеләр,
Йәстү[10] вакыты булганда,
Өйләр агып беттеләр.

Иртән халык эзләшеп,
Мәетләрне таптылар;
Коллар суы буенда
Тезелешеп яттылар.

Судлар килде, күрделәр.
Мәетләрне күмделәр.
Монда табылган хәтлесе
Егерме биш булдылар.

Мәетләрне күмделәр,
Зарарларын яздылар,
Язу язып, пичәт сугып,
Падишага салдылар.

Коллар авылы болыны
Мәет белән тулгандыр.
Мәхмүт байның зарары
Йөз кырык мең булгандыр.

Ай-һай, Оры байлары,
Бар да фабрик маллары,
Су эчендә җан бирүнең
Авыр икән хәлләре.

Ай-һай, Оры байлары
Агып киткән зур суга,
Ник акмасын ул суга,
Утырганнар уйсуга.

Агыйделнең буенда
Талга колмак бәйләнсен;
Бу бәетне чыгарганга
Алла рәхмәт әйләсен.

*Китаплар ага...*

Туфан булгач, билгеле, анда кешеләр һәм мал-мөлкәтләр генә агып калмый, анда халыкның заманынча культура кыйммәте булган әсәрләре дә агарга тиеш. Шулар эчендә китаплар да. Шуны да онытмыйк: XIX йөз башларынача патша хөкүмәте татарларга басма китап чыгарырга рөхсәт бирмәгәнгә, Олы аккан елларда да бездә басма китап бик аз, бөтен гыйлем-китап, әсәрләр язма рәвештә диярлек кулдан-кулга күчереп укыла. Шулай булгач, китап бик кадерле, бик кыйммәт. Оры исә – борыннан бирле галим-голәмә, абызлар, мәдрәсәләр шәһәре дә. Шуның өчен аның исеме дә Оры шәриф булган. XVII нче йөзнең мәшһүр язучысы галим Юныс Иванай ахун[11] кабере анда булса, Оры акканда, югарыда әйтелгән мәшһүр остаз Фәтхулла ахун[12], шулай ук башка абызлар, хәтта үзенә Пенза, Сембер губерналарыннан да мөритләр иярткән Хәбибулла ишан[13] да анда булалар. Анда мәдрәсәләр, заманынча галимнәр. Шулай булгач, Оры акканда, анда тарихи кыйммәтле кульязма әсәрләр, күчермәләр, дәреслекләр дә бик күп булган. Шунлыктан шәһәр акканда, кешеләр, маллар белән бергә ташкынга эләккән китаплар да күпләп ага. Бәеттә кайбер вариантларында бу хакта да әйтелә. Моны күреп, аһ-ваһка төшүчеләр бигрәк тә мәдрәсә шәкертләре булалар. Мәгәр шунысы да кызык: шәһәр агып китү кебек бу зур хәвефле хәлне тикшерергә шундук килеп җитүче колониаль патша хөкүмәте вәкилләре алдында алар гыйлем-китап әрәм булуга үзләренең борчылуларын сиздерсәләр, бу хәлне алар артында торган миссионерлар да сизәчәк, шуның өчен сер сынатырга ярамый дип белгәннәр һәм вәкилләр алдында эчтән тынганнар. Вәкилләр бәеттә дини аерма буенча гына «кяферләр» дип йөртеләләр, һәм шәкертләрнең дә алар алдында бу «сер»не сиздермәүләре әйтелә. Шәкертләр исә бәеттә «талипләр» (гыйлем эстәүчеләр) дип йөртелә. Менә алар хакындагы кайбер юллар:

[9] Бу юлларда байга ялланып, эшләп, шул акчага бүрек алыйм дип барган күрше авыл ялчы егетнең очраклы рәвештә туфанга эләгеп корбан булуы бик матур әйтелгән. (*Нәкый Исәнбәт искәрмәсе.*)
[10] *Йәстү* – шәфәкътан соң укыла торган намаз. (*Нәкый Исәнбәт искәрмәсе.*)

[11] Юныс Иванай ахун – дин эшлеклесе, Югары Оры авылында (хәзер Татарстанның Арча районы) имам-хатип, мөдәррис (1639 – 1689/1690) [24, 40–41 б.]. – *М.Х.*
[12] Фәтхулла ахун – Фәтхулла бине әл-Хөсәен әл-Орыви (1767/1768 – 1843), дин эшлеклесе [25, 6–10 б.]. – *М.Х.*
[13] Хәбибулла ишан – Хәбибулла бине Хөсәен әл-Орыви әл-Болгари (1762 – 1818), дин эшлеклесе [24, 84–85 б.]. – *М.Х.*

Талипләрнең зарарын
Һичбер кяфер белмәде.
Китапларның кодрәтен
Һич берәве сизмәде.

Күп Коръәннәр агыптыр,
Күп китаплар агыптыр,
Аны күргән талипләр
Зар вә гөрьян[14] булыптыр.

Талипләр күп еглады,
Остазларын җәлләде,
Бер Аллага дога кылып,
Җөмлә хәйран әйләде.

Шулай итеп, без бу юлларда, гәрчә заманынча дини төсмердәрәк булса да, без стихия корбаны булган гыйльми китапларга, мәдәни мираска мөнәсәбәтне һәм шәкертләрнең дә аның һәлакәтенә илнең рухи байлыгы һәлакәте кебек итеп карауларын, шул ук вакыт бу мәдәни мирасның барлыгын да шул туфан кебек басып юк итәргә карап кына торган Казан инквизитор миссионерларына да сер сынатмауларын күрәбез.

*1872 елгы Орының кичке күренеше ничек тасвир ителә?*

«Һава юеш вә гаять караңгы исә дә, якягыннан фабрикларның вә һәр тарафтан байлар уты болытларга төшеп, бөтен урамнарны яктыртып торадыр. Байлар ишегалдында карауччыларның, зур этләрнең калын тавышлары, чаң тавышлары, урамда торучы каравылчыларның шалтыравык тавышлары, узучы ямщикләрнең ат куган авазлары, кич йөрүче никрутларның гармуннар уйнап, акырып-сызгырган тавышлары…», аннары тагы шулай ук шәһәр дигәч тә, билгеле инде, аны һич кенә дә хәзергечә кала дип уйларга туры килми. Анда тау-тау йортлар, трамвай-машиналар, асфальт юллар да юк. Ләкин ул үз заманнарындагы авыл да түгел. Ул – капиталистик товар җитештерүнең чынлап та тәүге бер мануфактурачылык шәһәре. Ул үз тирәсендәге авыл гына булган авылларның берсенә дә охшамаган. Бәлки тормышы белән дә, күренеше белән дә Казан бистәләрен яки өяз-калаларның берәрсен күзалга китерерлек дәрәҗәдә бер шәһәрчек булган. Менә, мәсәлән, «Шәһри Казанә сәяхәт» [26][15] диген кечкенә бер китапчыкта, 1872 елгы Орының кичке күренеше ничек тасвир ителә:

«...Тышка чыктым. Фабрикчыларның тукмак тавышлары, ике су буенча тезелмеш гайре мөтәнаһи[16] каз-үрдәк тавышларына кушылып, болытлардан югары һаваларга чыга иде».

Бу әле сезгә үткән йөзнең 70 нче еллар Орысы. Ягъни аның бөлә-бөлә, ике генә фабрикка калган чагы күренеше. Оры үткән йөзнең, әмма 40 нчы елларына кадәр 6–7 фабрика белән гөрләп торган данлы-шанлы заманнарында аның шау-гөре ни дәрәҗәдә булгандыр, укучым үзе шуннан чамалый алыр, дип уйлыйм.

Шәһәр булгач, гел агач бинадан гына тормаска, анда таш пулатлар, магазиннар да булырга тиеш бит. Алар булганмы соң, Шәрифҗан Габдулла углының истәлек дәфтәрендә болай язылган:

«Байларның таш амбарлары, складлары тулы каракүл, кытат, бәз, кызыл товарны әйткән дә юк, таш подвалларда хәтта казахтан китерелгән карынлы куй майлары өелеп ята».

«Мөэмин бай Хуҗа Сәетовның[17] да таштан зур подваллары булган. Хәтта акча сукрырырга дип тә хыялланганнар. Садыйк Хуҗа Сәетов фабрикалары да таштан, күп эшчеләре булган. Капка, коймалары, складлары, кибетләре дә таштан булып, һәр таш кибет магазин исемендә, һәр төрле товар булган» [11].

Моннан күренүенчә, үткән йөз башларында һәм урталарындагы Оры агач һәм таш өйләр белән аралаш булып, гомуми күренеше белән Казанның Иске бистәсен хәтерләтә торган бер шәһәрчек булган дип күзалга китерә алабыз.

Шул ук вакыт Оры элеккечә авыллыгыннан аерылып җиткән дип тә уйлый күрмәгез, һич юк. Шунда ук берәүләр авыл хуҗалыгы да алып баралар, терек-туар да, бакча да тоталар, иртән көтү дә чыгарып, кичен аны да каршы алалар. (Хәер, мин Оры юлларын җәяүләгән бу 1938 елларда Казанның үзендә дә сыер тоту, көтү асрау әле дә дәвам иткәнгә, элекке Орыда бу хәлләрнең баруы аның шәһәрлегенә зыян итмәвенә һич ис китәргә ярамый.) Кайсы байларның өере-өере белән атлары да бар иде. Һәркайда зур урманнар, дачалар тоталар, Битаман, Җанбай, Нирти урманнары Оры байлары милкендә иде. 50–60 чакрым җирдә

[14] *Гөрьян* – зар-зар елаучы. (*Нәкый Исәнбәт искәрмәсе.*)

[15] «Шәһри Казанә сәяхәт», 1902 ел, авт. Б.Г. С.С. (Бу хәрефләр дә әлифбабызда хәрефләр җитмәгәнгә үзенчә генә күрсәтелә). (*Нәкый Исәнбәт искәрмәсе.*)

